

Икенче октябрьдә Владимир Чибиркин рәислегендә Мордовия Дәvләт Жыенынын чираттагы сессиясе узды. Анда тобәк Хокvмәте әгъзалары, хакимиятнен башкарма органнары һәм жирле vзидарә органнары житәкчеләре катнашты.

Утырыш башында III дәрәжә Мордовия Республикасы Дан ордены Юрий Тутуковка vлгәннән сон тапшырылды. «Юрий Васильевич быел июль аенда вафат булды. Ул социаль сәясәт комитеты һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссия составында эшләде. Республика законнарын камилләштерvгә зур олеш кертте. Анын исеме Торбеево ит һәм сот сәнәгате коллиятенә бирелгән, анда Юрий Васильевич ярты гасырдан артык эшләгән», – дип искә тошерде Владимир Чибиркин. Бvләкне депутатнын тол хатынына тапшырдылар.
Сессиядә кон тәртибендәге 16 мәсьәлә каралды. Жәмәгать тәртибен һәм гражданнарнын унайлы яшәv шартларын тәэмин итv максатыннан «Мордовия Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату әйләнешен дәvләт жайга салуы турында»гы законнын 7 статьясына vзгәрешләр кертелде. Кvпфатирлы йортларда һәм аларга якын территорияләрдә урнашкан жәмәгать туклануы йортларында (ресторяннардан тыш) 23 сәгатьтән 9 сәгатькә кадәр алкогольне ваклап сату тыела. Карар «псевдокафе» һәм «псевдобарлар» санын киметv очен кабул ителгән. Анда жәмәгать туклануы хезмәтләрен кvрсәтv сылтавы белән тонлә ваклап сатуга ачылган тарада алкоголь продукциясе сатыла.
Мордовия прокуроры инициативасы белән гражданнар, вазыйфаи һәм юридик затлар очен муниципаль берәмлекләрнен террорчылыкка каршы комиссияләре карарларын vтәмәгән яки бозган очен, шулай ук кабат шундый хокук бозулар очен административ жаваплылык билгеләнә.
Мәгариф министры Елена Солдатова тәкъдим иткән «Мордовия Респуб-ликасында бюджетара монәсәбәтләр турында» гы законнын 15 статьясына vзгәрешләр хупланды. Алар тәрбия һәм балалар ижтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директорлар кинәшчеләренә айлык акчалата тvләvләрне арттыруга кагыла. Шулай ук Мордовия Дәvләт Жыенынын социаль сәясәт комитетынын Боек Ватан сугышы чорында тылда эшләгән затларга айлык акчалата тvләv кvләмен арттыру турындагы инициативасы да хупланды.

Аерым законнарга салым һәм инвестиция сәясәте олешендә vзгәрешләр кертелде. Региональ инвестиция проектларында катнашучы оешмаларга табышка салым һәм оешмалар молкәтенә салым буенча ташламалар биреләчәк.
«Мордовия Республикасы террито-риясендә жир монәсәбәтләрен жайга салу турында»гы законга кертелгән vзгәреш тобәк инвестпроектларында катнашучы оешмаларга жирләрен торглар vткәрмичә генә арендага бирvне кvздә тота.
Үзгәрешләр Мордовиядәге юл эшчәнлегенә дә кагылачак. Вәкаләтле башкарма хакимият органына (Уполномоченный орган исполнительной власти) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл йорv кагыйдәләрен теркәv чараларын урнаштыру, сvндерv һәм сvтv турында карарлар кабул итv вәкаләте бирелә (по принятию решений о размещении, отключении и демонтаже средств фиксации ПДД на автодорогах общего пользования).